Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ МУРТЫШ-
ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯСАРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ
МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

25.01.2016 ел № 6

Мортыштамак ав.

Референдум уздыруны инициациялəү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һəм референдумда катнашу хокукының төп гарантиялəре турында» 2002 елның 12 июнендəге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендə җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендəге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Мортыштамак авыл җирлегенең 11 ст. нигезендə Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге советы КАРАР ИТƏ:

1. Җирле референдум уздыруны түбəндəге сорау буенча инициациялəргə: 2015 елда Мортыштамак авыл җирлеге территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн I төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан башка балигъ булган һəр кешедəн, җирле əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə алынган акчаларны түбəндəге эшлəрне башкару буенча хəл итүгə 200 сум күлəмендə үзара салым кертүгə ризамы:

- җирлекнең торак пунктлары чиклəрендə беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тəэмин итү;

- җирлек территориясендə физик культураны һəм массакүлəм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рəсми физкультура-савыктыру һəм спорт чараларын үткəрүне оештыру;

Җирлек халкын мəдəният оешмалары хезмəтлəре белəн тəэмин итү һəм ял итү өчен шартлар тудыру

җирлек территориясен төзеклəндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшеллəндерүне, урамнарның исемнəре һəм йортларның номерлары белəн күрсəткечлəр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны да кертеп);

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

-җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

-җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Сарман муниципаль районы

Мортыштамак авыл җирлеге

Совет Рәисе: Әхмәтгәрәев М.Н